ЧАЛЛЫДА ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН
Рөстәм Миңнеханов автокалада инновацион проектлар белән танышты
> 2

МАЛ КАДЕРЕ
Татарстанда 19 район гына терлекләр санын арттыруга ирешкән
> 2

КАМИЛ СӘГЪДӘТШИН:
«Мин шигырьне төшемдә күрәм»
> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 28 (28801) | Шимбә | 26 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Хәерле юл!

Яшерәсе юк: юл-транспорт һәлакәтләренең шактый өлеше салмыш хәлдәге машина йөртүчеләр гаебе белән килеп чыга. Андыйлар турында халык социаль челтәр аша хәбәр итә ала. Хәбәр итәләр дә! Узган ел Татарстанның ЮХИДИ идарәсе 440 хатны «Телеграм» аша кабул иткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ӘЛӘК ТҮГЕЛ, КИСӘТҮ

Кисәтү кулайрак?

Ерак юлларга йөрүче татар «дальнобое» Назыйм Галимов исерек хәлдә машина йөртүче кешеләрне бер дә хупламый. Алар белән очрашса, битараф калмам, ди. Тик кемгәдер шалтыратып, язып хәбәр итәргә җыенмый. Озын юллар үтүче әңгәмәдәшебез моның сәбәбен болайрак аңлата:

– Әләкләү миңа хас түгел. Исерек килеш машинага утырган кешеләрне күрә калсам, иң яхшы ысул – яннарына барып кисәтү ясау, минемчә. «Күрдем, хәзер тиешле урынга әйтәм, рульгә утырма», – дип, мәсәлән. Кеше икеләнеп куярга мөмкин. Исерек кеше әле анысын да аңламаска, борынына кундырырга да күп сорамас. ЮХИДИ хезмәткәрләренә әләкләсәң, ул кеше белән проблемалар килеп чыгуы ихтимал. Эчәсең икән, такси чакырт, «Аек шофер» хезмәте бар. Хәмер капкансың икән, рульгә ябышма, кырыйда утыр йә бөтенләй юлга чыкма.

Назыйм Галимов машина иярли торган кешеләргә өйдә алкотестер тотарга киңәш итә. «Кыйммәт тә тормый ул. Әйтик, кичтән азрак салдың икән, иртән өреп карыйсың да тикшерәсең. Организмыңда алкоголь булмаса, тынычлап машинаңа утырасың. Бар икән, тыелырга кирәк. Бу кыен түгел бит», – ди ул.

Кем икәнеңне белмиләр

Татарстанның баш дәүләт автоинспекторы Ленар Габдрахманов «Телеграм» каналы аша ЮХИДИ вәкилләренә тәртипсез кыланган машина йөртүчеләр турында мөрәҗәгать итеп булуын журналистлар белән бер очрашуында әйткән иде. Ул чакта бер матбугат вәкиле: «Исерек хәлдәге машина йөртүчегә юлыктым, тиз арада вәкаләтле органнарга җиткерү мөмкинлеге бармы?» – дип сорашты. «Әләкләү булмасмы?» – дип тә кызыксынды.

Болар бәрабәренә кеше гомерен саклап калу ихтималы артуы турында сүз барганда әләк дигән төшенчәне куллану урынлымы икән? Хәмер эчкән килеш рульгә ябышканда башка әхлак-әдәп кагыйдәләре онытыла бит әле.

Узган ел ЮХИДИ хезмәтенең «Телеграм» каналы сәрхуш килеш юлга чыгучылар турында 440 хәбәр кабул иткән. 101 кешене административ җаваплылыкка тартканнар. Бу елның гыйнвар аена 60 хәбәр килеп ирешкән. Машина йөртүче сәрхушләрнең 29ын җавапка тартканнар.

Бу ысулдан һәр районда файдалана алалар. Хокук саклау органнары анонимлык саклаячагын әйтә. Ягъни теге яисә бу очрак турында кем хәбәр иткәнен алар гына беләчәк. Мәгълүматны фото һәм видеосурәт белән тулыландырсаң, тагын да яхшырак. Җирлеккә карап, дөрес каналны табу өчен, «Телеграм» кушымтасының эзләү өлешендә «ГИБДД» сүзен язарга һәм аннан соң тиешле район-шәһәр атамасын өстәргә кирәк. Мисал өчен, «ГИБДД Казань».

Гомумән, Дәүләт автоинспекциясе вәкилләре исерек килеш машина йөртүчеләр мәсьәләсенә битараф калмаска сорый. Социаль челтәрләр белән дус булмаганнар, **112, 02** яки **8 (843) 533-38-88** телефоннары аша да мөрәҗәгать итә ала.

Исерек килеш машина йөртүчеләргә каралган штрафлар турында да искәртик. Әйтик, андыйларга 30 мең сум штраф, 2 елга кадәр машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм итү яный. Әгәр дә юл һәлакәтендә зыян күрүчеләр бар икән, Россия Җинаять кодексының 264 маддәсе буенча җәза көтә.

Нишләтергә сезне?!

Салмыш хәлдәгеләр машинага утырмасын, шул килеш юлга чыкмасын өчен нишләргә? Бу сорауга төрле фикер-тәкъдимнәр ишетергә туры килде һәм туры киләчәк тә.

Әйтик, Татарстанның вице-премьеры Шамил Гафаровның исерек килеш машина йөртү аркасында тоткарланган кешеләрне телевидениедән күрсәтергә кирәк дип тәкъдим иткәне бар. Аракы томалаган акылны шул уятыр, шәт. «Бу бит – хурлык. Бер генә түгел, атна буе күрсәтергә кирәк», – дип саный Шамил Гафаров.

Заманында Россия Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин сәрхушләр катнашындагы үлемгә китергән аварияләрне аңлы рәвештә кеше үтерүгә тиңләргә тәкъдим итте. «Исерек килеш машинага утыргансың икән, димәк, ниятең бар», – дигән фикердә сәясәтче. Моннан тыш та машина йөрткәндә тәртипсез кыланганнар өчен җаваплылыкны катгыйландыру турында берничә тапкыр сүз катканы булды әле парламентарийның.

...Бу дөньяда озак яшәмим, тик шул гомерем эчендә салмыш килеш рульгә ябышучылар аркасында берничә якын кешем күргән зыян-хәсрәтне бергә кичерергә туры килде. Очракларның берсендә икенче дистәсен яңа тутырган иптәшебезне мәңгелеккә озаттык, машинада булганнарның икесенә берничә тапкыр катлаулы операция кичерергә, психологик яктан тернәкләнергә туры килде. Ә югалту ачысын ничек дәваларга?

Сәрхуш аркасында тагын бер иптәшебез чактан гына аяксыз калмады. Операция ясату өчен акча җыйдык, әлеге дә баягы тормышка кире кайтару этабын уздык.

Гаеплеләр исә тыныч яшәвен дәвам итә. Кайсылары яңа фаҗигаләр китереп чыгара. Җәзасын алганнан соң, шешәгә «хуш» диючеләре сирәк бит. Юллар гына һаман канга буяла...

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

◆2021 елда психик тайпылышлары һәм нерв системасы авырулары булган, шул исәптән алкоголь кулланган 3085 заттан машина йөртү таныклыгы тартып алынган. 378 кешегә карата транспорт чаралары белән идарә итү хокукын бирүне туктату турында карар чыгарылган.

◆2021 елның 9 аенда ЮХИДИ хезмәткәрләре Татарстанда исерек килеш рульгә утырган 10676 кешене туктаткан. 897 кеше бу хәлендә икенче мәртәбә тотылган.

РӨХСӘТ ИТЕЛМӘГӘН ХӘМЕР КҮЛӘМЕ

➤1 л канга 0,3 граммнан артыграк этил спирты;

➤1 л өрелгән һавада 0,16 миллиграммнан артыграк этил спирты.

Бурыч түләү – үзе бурыч

Узган елда Татарстанда суд приставлары 16 миллиард сум күләмендә бурыч түләткән. Федераль суд приставлары идарәсе җитәкчесе Әнвәр Закиров әйтүенчә, 2021 елда эш документлары саны 7 процентка арткан (3 миллион чамасы). Бер суд приставына уртача 7 меңнән артыграк эш туры килгән. Идарә хезмәткәрләре алимент түләтү мәсьәләсен аерым игътибар үзәгендә тота. Узган елда балаларга барлыгы 561 миллион сум күләмендә алимент акчасы түләтелгән. Бу 2020 елдагыга караганда 234 миллион сумга күбрәк. Гыйнвар аенда салым буенча 113 миллион сумга якын бурыч түләтүгә ирешелгән.

Федераль суд приставлары хезмәте узган елда кешеләрнең банкларга бурычы буенча 8,6 миллион эш кузгаткан. 2012 елдан бирле хезмәтнең статистикасын алып бару чорындагы иң зур сан бу.

Ярминкәләрне көтәбез

19 марттан, Президент Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча, Татарстанда авыл хуҗалыгы ярминкәләре яңартып җибәрелә. Бу хакта авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров белдерде. Аның сүзләренә караганда, узган елда үткәрелгән ярминкәләрдә барлыгы 1,9 миллиард сумлык товар сатылган. Министр искәрткәнчә, ярминкәдә катнашучыларга транспорт чыгымын каплау авыл хуҗалыгы продукциясен арзанрак бәядән сату мөмкинлеге бирә.

Сырхауханәләр гадәттәгечә эшли

Татарстан сырхауханәләрендә халыкка диспансеризация үткәрү һәм планлы медицина ярдәме күрсәтү яңартып җибәрелде. Коронавирус кичерүчеләргә тирәнтен диспансеризация, профилактика тикшеренүләре дә үткәрелә, дип хәбәр итә Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте. Моннан тыш 28 февральдән «Мобиль поликлиника» күчмә комплексларының эше дә торгызыла.

Исегезгә төшерәбез: 2 февральдән республикада, коронавируска бәйле хәлләрнең катлауланувы сәбәпле, планлы медицина ярдәме күрсәтү һәм диспансеризация уздыру туктатылган иде.

Яз җылысы килә

Быелгы кыш бу гасырның иң карлы кышлары өчлегенә кергән. КФУ Экология һәм табигатьтән файдалану институтының метеорология кафедрасы профессоры Юрий Переведенцев шулай дип белдергән. Татарстанда 2021–2022 елгы кыш айларында һава торышына Төньяк Атлантикадан даими үтеп керүче циклоннар йогынты ясап торган икән. Шул ук вакытта, Переведенцев әйтүенчә, без алардан читтәрәк калып киләбез. Димәк, һава торышына бәйле күңелсезлекләр безгә азрак эләгә. Профессор сүзләренә караганда, март аенда да, элеккечә үк, Атлантика циклоннары өстенлек итсә, язның беренче ае җылы булачак, кар тиз эреячәк. Бу хәл кайбер урыннарда су басуга китерергә мөмкин.

Февральнең соңгы көннәрендә республикада көндез 2 градуска кадәр җылы торачак. Гомумән, быел инде каты суыклар көтелми. КФУ доценты Тимур Әүхәдиев әйтүенчә, мондый һава торышы нормадан 11 градуска югарырак. Бездә ул март ахыры – апрель башына хас.

Якшәмбе – 27 февральдә төнлә – 3 – 8 градус суык, көндез 2 градус җылы һава көтелә.

COVID-19

Төнлә биергә ярамый

Чикләү бетте, чир китте... диясе түгел. Роспотребнадзор белгечләре әйтүенчә, коронавирус белән авыручылар саны кабат үсә. Узган атна белән чагыштырып караганда, бу күрсәткеч 21 процентка җиткән. Штаммнар һөҗүме дәвам итә.

Татарстан бу атнаны QR-кодсыз гына үткәрде. Чикләү чарасының бу төре гамәлдән чыгарылса да, әле башкаларыннан баш тарту турында уйларга иртәрәк, диләр.

– Клуб, кафе-ресторанннарның төнге эшчәнлеген рөхсәт итү турында сүз юк әле. Без эпидемиологик таләпләрне бозу очракларын ачыклау буенча даими эш алып барабыз. Узган атнада 88 очрак теркәлде. 313 мең сумга административ штраф салынды, – диде Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина.

Битлек кию, сакланып йөрү комачау итмәс анысы. Шул исәптән вакцинация дә. Соңгы мәгълүматлар буенча, республикада 2460617 кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан. Бу – халыкның 80,77 проценты дигән сүз. 1925700 кеше прививканың икенче дозасын алган. Кабат вакцина ясатучылар саны – 243499 кеше.

Азрак, әмма җитдирәк авырыйлар. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы коронавирус белән хәзер чирләүчеләрне шулай тасвирлады. Сүз уңаеннан, узган тәүлектә коронавирус йоктырган 2545 кеше теркәлгән.

– Сырхаулар саны азаюга карамастан, чирне катлаулы кичерүчеләр күп. Табиблар да хастаханәгә уртача һәм авыр формада авыручыларның эләгүен әйтә. Шуңа күрә коронавирус юкка чыкты дип булмый әле, – диде министр урынбасары Владимир Жаворонков.

COVID янында грипп та бар бит әле. Әйтүләренә караганда, анысы инде чигенә. Авыручылар саны кими бара. «Узган атнада грипп белән авыручылар күрсәткече 31 процентка кимеде. Эпидемиологик сезон ахырына якынлаша дип әйтергә була», – дип ышандырды Любовь Авдонина.

Киләсе яңалык йөкле хатыннарга файдалы булыр. Бәби көткән хатын-кызларның сәламәтлеген хәзер «Связь» дип аталган махсус мобиль кушымта аша күзәтеп тору мөмкинлеге бар. Булачак әниләр медицина вәкилләренә үзләренең хәле турында мәгълүматны өйдән чыкмыйча гына тапшыра алачак.

– ОРВИ билгеләрен ачыклау өлешендә хәбәрләр көтеп утырмас өчен, социаль челтәрләрдән файдаланырга һәм шулар аша гүзәл затларыбызның хәлләрен сорарга булдык, – ди бу җәһәттән Владимир Жаворонков.

Кушымтаның «атасы» Вадим Шитов әйтүенчә, «Связь»-га 2 меңләп хатын-кыз кушылган инде.

– Алар кушымтада анкета тутыра, анда тән температурасы күрсәткече, өйдә авыручылар бармы-юкмы икәнен күрсәтә. Бу исә безгә, чир була калса, аны башлангыч стадиясендә үк ачыкларга, йөкле хатын-кызны вакытында белгечкә билгеләргә мөмкинлек бирә, – ди ул.

Сүзгә-сүз

Анатолий АКСАКОВ, Россия Дәүләт Думасының Финанс базары комитеты рәисе:

Банк һәм банкоматлардан акчаны алырга мөмкин, билгеле. Ләкин мин аның мәгънәсен күрмим. Ник дигәндә, Үзәк банк вазгыятьне контрольдә тота. Икенчедән, түләү карталарының илкүләм системасы бөтен транзакцияләрне, шул исәптән халыкара түләү системасы карталары аша үткәрелгәнне дә башкара. Халыкка һәм оешмаларга өзлексез хезмәт күрсәтү өчен барлык шартлар да тудырылган.

(«Парламентская газета»га биргән интервьюсыннан)

РОССИЯДӘ СӘЯХӘТКӘ МӨНӘСӘБӘТ

Россия халкы сәяхәткә азрак акча тота башлаган. Бу хакта «Райффайзенбанк» үткәргән сораштыру нәтиҗәләре сөйли. Сәяхәткә мөнәсәбәтне коронавирус чикләүләре аркасында үзгәртергә туры килгән.

51%	сәяхәткә дигән маяны киметкән
28%	үзгәреш сизмәгән
21%	сәяхәткә чыгымны арттырган

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

«Алтын гасыр» кайтырмы?

Без постиндустриаль дип аталган җәмгыятьтә яшибез. Ягъни җитештерү беренче планда тормаган, төрледән-төрле хезмәт күрсәтү алга чыккан чорда. Ләкин бу заводларны ябарга, фабрикаларны туктатырга, сәнәгать белән шөгыльләнмәскә дигән сүз түгел. Ул өлкәләр дә бик кирәк. Безнең ил дигәндә бигрәк тә. Памперслардан башлап катлаулы станокларга чаклы барын да нефть долларларына читтән сатып алып та яшәп буладыр, әлбәттә. Тик ул булдыклылар шөгыле түгел. Постиндустриаль чорда да үзен хөрмәт иткән дәүләт сәнәгатькә үтә дә игътибарлы булырга тиеш. Ә заманча сәнәгать һәр очракта да квалификацияле хезмәткәрләр, кадрлар белән бәйле. Катлаулы станок янына басып деталь эшкәртүче әзерлекле эшчеләр, заманча технологияләргә корылган җитештерүне иярли алган инженерлар, идарәчеләр белән.

Соңгы араларда нәкъ менә шуларга кытлык ялганын искәртә башладылар. Ил масштабында да, без яшәгән республикада да. Яңа ел алдыннан гына КамАЗ җитәкчесе Сергей Когогин автогиганттагы әзерлекле кадрлар дефициты хакында чаң каккан, ул кытлыкны коллапска тиңләгән иде. КамАЗ кебек югары технологиягә корылган сәнәгать предприятиеләре илдә адым саен булмаса да, шөкер, бар. Россия Сәүдә-сәнәгать палатасы (ТПП) февральдә үткәргән киңәшмәдә дә зур предприятие җитәкчеләре кадрлар проблемасының кискен торуын ассызыклаган. Шунысы да ачык: мәсьәлә якын араларда хәл ителми икән, бездәге болай да мактанырлык булмаган икътисад тагын да мөшкелләнергә мөмкин. Ә ул хәл, үз чиратында, халыкның тормыш дәрәҗәсенә, сыйфатына китереп сугачак.

Язып торуларынча, илдәге еллык икътисад үсеше 1,5 процент тирәсе. Елына 5–7 процентка үскән Кытай, 3–4 процентка күтәрелгән Европа берлеге белән чагыштырганда бу бер дә куанырлык сан түгел. Шул ук Кытай – бижутериядән башлап, сәгатенә 300 чакрым тизлек белән чабучы электровозларга чаклы җитештереп торучы галәмәт олы завод, очсызлы продукция белән ярты дөньяны тәэмин итеп, инде күпләрне ялкаулыкка, ваемсызлыкка өйрәтте. Чимал сатып көн күрүчеләрне, бәлки, бик өйрәтеп торасы да булмагандыр. Бүгенге глобаль икътисад, җитештерү дигәндә, ниндидер уйланылган, гадел халыкара, илара кооперация хакында сүз алып барып булмый. Сәяси вазгыять үзгәреп тора, сәясәттәге турбулентлык икътисадны тотрыксызландыра. Кемнәрдер нәрсәнедер сатмый башларга да мөмкин. Булдыра алган кадәр ассортиментны үзеңдә җитештерү мөһимлеге бәхәссез. Андый икътисади сәясәтнең бүгенге Россиядә иseме дә бар. Ул импортны алыштыру дип атала. Андый хәлләрдә әзерлекле кадрларга, яхшы белгечләргә ихтыяҗ ныграк та арта. Чөнки читтән кертеп килгән, соңрак биредә җитештерелә башлаган продукция гадәттә катлаулы технологияләр белән бәйле.

Кадрлар кытлыгын якын арада җиңеп булырмы? Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс, ди татар мәкале. Бүгенге яшь буын һөнәр сайлаганда соңыннан ак яка киеп офиста утырырдаена өстенлек бирә. Чөнки җитештерү – җитештерү, завод завод инде, анда тимер-томыр, станок шавы, яшьләр яратып бетермәгән дисциплина һәм тәртип. Өстәвенә әле сызымнарны, электрон схемаларны яхшы белергә, төрледән-төрле технологик документация белән эшләргә өйрәнергә, шулар белән баш катырырга кирәк. Саналганнардан артык курыкмаслар да иде бәлки, түләү ягы да әллә ни түгел. Хезмәт хакы дигәндә, нефть сәнәгатендә дә артык юмартланмыйлар. Нефть институтын тәмамлап, автосалонда машина сатучы менеджерның: «Кырда, скважиналарда пычранып йөргәннәрдән күбрәк алам әле мин», – дип мактанганы истә.

Элек бергә эшләгән танышларым еш кына җитештерү өлкәсен сайлап, эшкә килгән яшь белгечләрнең дә белеме сай булуга, бер ел да эшләмәстән тәртәне башка якка боруларына зарлана. Ник шулай? Бу сорауны, ихтимал, кичәге студентлардан да бигрәк вузларга, Мәгариф министрлыгына бирү дөрестер. Вузларның хәтсезе түләүле бүлекләр ачып, акча эшләү белән мавыгуын дәвам итә. Мин яшәгән шәһәрдәге КНИТУ филиалы шәһәрнең 14 мәктәбен бетергән барлык «өчле» капчыкларын да дипломлы итеп бетерде бугай инде. Акча түләп алынган белем дә сыйфатлы булырга тиештер дә бит. Юк, әлегә алай түгел. Кичәге мәктәп баласы да, вуз җитәкчелеге дә бер юнәлештәрәк уйлый, күрәмсең: кеше биш ел буе кирәкле сумманы түләп торган икән, аны ничек дипломсыз калдырмак кирәк?! Студент белем өчен укымый, диплом өчен тырыша булып чыга. «Катыргы» алгач та ул, гадәттә, үз белгечлеге буенча эш эзләми. Эшләр дә иде, ул өлкәдә аның наданлыгы кычкырып тора. Ул сәүдә, кибет тирәсенә елыша, хезмәт күрсәтү сферасын, бизнесны сайлый. Диплом иясе булып алган андый зат ни эшләсә дә эшли, завод тирәсенә, нефть оешмасына, андагы «кара эш»кә бармый. Ул бит зәңгәр яка – спецовка кияр өчен дәрәҗәле вуз бетермәде. Тик менә «шабашка» белән мавыккан андый институтларны дәрәҗәле дип әйтеп була микән? Әгәр вузлар акчага диплом өләшмәсә, «көчле өчле»гә укыганнар көллиятләргә, техникумнарга барыр иде. Бүгенге токарьлар, фрезерчылар, электр белән эретеп ябыштыручылар, слесарьлар кытлыгы алай ук кискен тормас иде.

Җәмгыять, заман яшьләрне үзе «халява»га, җиңелгә өйрәтми микән? Яшьләр гадел булмаган юллар белән бик тиз генә баеп киткәннәрне күрәләр. Гомере буе авыр хезмәттә тир түгеп тә һаман мантый алмаган әти-әниләре дә яннарында гына. Социаль лифтлар эшләмәгәндә, белемнең уңыш гарантиясе булмаганын да аңлый алар. РФ хөкүмәте каршындагы Финанс институты профессоры сөйләгән кызык та, кызганыч та хәл истә калган. Яшьләр кулындагы гаджетлар да бер бәлагә әйләнгән икән. Оборона предприятиеләрендә аларны тапшырып керәсе. Яшь җилкенчәк телефоннарсыз паника, стресс кичерә башлый, эшли алмый икән. Кесәсендә телефон булганда исә, яшь кавем хәл итәсе мәсьәләне башында 2–3 сәгатьтән артык тота алмый.

Әле демографиянең дә киресе бар. Ил халкының үткән 2021 елда гына бер миллионнан артык кешегә кимүен рәсми чыганаклар да әйтеп тора. Кадрлар, җитештерүдә хезмәт куючылар проблемасы тагын да кискенләшмәсен дигәндә, дәүләтнең бу юнәлештә бар якны да исәпкә алган махсус программа кабул итүе кирәктер.

tatarstan.ru

ЧАЛЛЫДА СУЫТКЫЧКА ДА «АКЫЛ» КЕРӘ

Кибеттән азык-төлеккә заказ бирергә «өйрәнгән» суыткыч, тән тиресендәге шешне 140 тапкыр зурайтып күрсәтү мөмкинлеге биргән медицина җиһазы. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Чаллыга эшлекле сәфәре кысасында шәһәр предприятиеләре һәм оешмаларының продукция күргәзмәсендә әнә шундый җиһазлар белән танышты. Ул шулай ук Чаллы мэры һәм КамАЗ генераль директоры белән КамАЗның җитештерү мәйданчыкларында булды, Чаллы шәһәр советы утырышында катнашты.

Балалар һәм яшьләр иҗат сарае фойесында оештырылган күргәзмәдә 20дән артыграк предприятие һәм оешма инновацион эшләнмәләр, технологияләр тәкъдим иткән. Проектларның күпчелеге цифрлаштыру өлкәсенә карый.

Күргәзмәдә шулай ук «Татэлектромаш» холдингының GELIOMASTER компаниясе стенды урын алган. Компания һаваны бактерияләрдән чистарту өчен билгеләнгән ультрашәмәхә нурланыш җиһазларын җитештерә. Әлеге продукциягә Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә ихтыяҗ зур.

Татарстан Президентына азык-төлеккә заказ бирергә «өйрәнгән» Haier «акыллы» суыткычы да күрсәтелде. Haier компаниясе нәкъ менә шундый суыткычлар җитештерүгә әзерләнә. Аның өч төрле моделен эшләп чыгару планлаштырыла.

Чаллы онкология диспансеры баш табибы Алмаз Хаҗиев тән тиресендә яман шешне ачыклауда ясалма акылдан файдалану турында сөйләп үтте. FotoFinder җиһазы диагнозны максималь дәрәҗәдә дөрес кую мөмкинлеге бирә. Аның видеодерматоскобы теләсә кайсы шешне 140 тапкыр зурайтып күрсәтә (чагыштыру өчен: дерматоскопларның күпчелеге 10–40 тапкыр гына зуррак күрсәтә ала).

Соңыннан Рөстәм Миңнеханов Чаллы шәһәр советының узган елдагы эш йомгакларына, быелгы бурычларына багышланган утырышында катнашты. Ул үзенең чыгышында шәһәрнең Татарстан муниципаль районнары социаль-икътисади үсеш рейтингында төзелеш, җитештерелгән продукция күләме буенча – икенче, үзе җитештергән товарлар белән тәэмин итү күләме буенча дүртенче урында торуын билгеләп үтте. Президент әйтүенчә, Чаллы КамАЗ, «Даймлер», «Риат» кебек сәнәгать предприятиеләренең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә рейтингта алдынгы урыннарны били.

Шул ук вакытта Рөстәм Миңнеханов «Чаллы» социаль-икътисади үсеш ягыннан алга китешле территория (ТОСЭР) өчен яңа мөмкинлекләр табарга кирәклеген искәртте. «Кече бизнесның тулай җирле продукты өлеше хәзер 34,7 процент тәшкил итә. ТОСЭР тагын да активрак эшләсә, әлеге күрсәткеч югарырак булачак», – диде ул.

Президент шәһәр хезмәтләренә торак-коммуналь хезмәтләрне, юллар торышы, транспорт хезмәтен аерым игътибар үзәгенә алырга тәкъдим итте. Ул шулай ук үсеп килүче буынны тәрбияләү темасына тукталып үтте, Чаллыда белем бирү системасының иң яхшылардан берсе булып торуын басым ясап әйтте.

Татарстан Президенты билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта республикада бик күп социаль программалар тормышка ашырылып килә. Әйтик, юл төзелеше өлкәсендә, Чаллы һәм Түбән Каманы читләтеп, Кама елгасы аша күпер белән, М12 автомобиль юлы, Шәле – Баулы юлы төзелә. «Республика тарихында моның кадәр күп юлларның әле беркайчан да төзелгәне булмады. Бу проектларның барысының да тормышка ашачагына ышанам», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Остазына күрә шәкерте

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Россия лидерлары» идарәчеләр бәйгесенең суперфиналистлары белән очрашты. Республика җитәкчесе әлеге чараны илдә талантлы җитәкчеләрне ачыклау һәм үстерү буенча кызыклы һәм кирәкле мәйданчык дип атады. «Без Татарстанда «Россия лидерлары» бәйгесенә һәрвакыт аерым игътибар бирәбез, безнең финалистлар белән тыгыз эшлибез», – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов. Очрашуда республика өчен мөһим булган төп һәм мөһим тармакларда җиңү яулаган Татарстан вәкилләре катнашты. «Дәүләт идарәсе» трекында җиңүче Алексей Морозов Рөстәм Миңнеханов канаты астында остазлык программасы үтәргә теләвен белдерде. Егет спортны популярлаштыру буенча проект эшләргә җыенуын да әйтте. Исегезгә төшерәбез: «Россия лидерлары» идарәчеләр бәйгесенең суперфиналы 24–27 март көннәрендә Мәскәүдә узачак. Анда бөтен Россиядән 300гә якын кеше катнашачак. Анда 100 җиңүче ачыкланачак. Әлеге бәйгедә җиңүчеләргә идарәчеләр буларак ихтыяҗ зур. Әйтик, узган сезонда 17 финалист арасыннан 12се шушы вазыйфага билгеләнгән. Беренче сезон җиңүчесе Александра Лебедева күптән түгел Камчатка крае Хөкүмәте Рәисе урынбасары итеп билгеләнде. 2018 елда ул Рөстәм Миңнехановның остазлык программасын үткән иде.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Президенты **Миңнеханов** Рөстәм Нургали улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлары өчен» II дәрәҗә ордены** белән бүләкләнде.

Мөмкинлекләр тагын да зуррак

Дәүләт Советы Рәисе, Россия Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары буенча комиссиясе рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко җитәкчелегендәге Россия делегациясе составында Таҗикстанда булды. Ул Дүшәнбе шәһәрендә «Таҗикстан – Россия: төбәкара хезмәттәшлек мөмкинлекләре» парламентара форумда катнашты. Парламентчылар Россия белән Таҗикстан арасындагы хезмәттәшлек, парламентара, икътисади һәм гуманитар элемтәләрне киңәйтү мәсьәләләрен карады.

Быел Россия белән Таҗикстан арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырылуга 30 ел тула. «Дәүләтләр хезмәттәшлек буенча зур тәҗрибә туплады, бүген бу хезмәттәшлек күп төрле һәм ике як өчен дә файдалы», – диде Валентина Матвиенко.

Фәрит Мөхәммәтшин, форумда катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, Татарстанның Таҗикстан белән күптәннән хезмәттәшлек итеп килүен билгеләп үтте.

– Соңгы дүрт ел эчендә товар әйләнешенең даими үсеп, узган елда 19,5 миллион доллар тәшкил итүен генә әйтү дә җитә, – диде ул. – Таҗикстанда безнең нефть химиясе, шин продукциясенә зур кызыксыну күрсәтелә. Ә инде Татарстанда Таҗикстан җитештерүчеләренең продукциясенә, җиһазларына ихтыяҗ зур. Әмма хезмәттәшлегебез мөмкинлекләре тагын да зуррак дип уйлыйм.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Татарстан Таҗикстан белән бик зур гуманитар элемтәләргә ия. Хәзерге вакытта анда 15 меңгә якын татар яши. Инде 1988 елда ук Татарстан Халыклары ассамблеясы кысасында оештырылган таҗикларның милли-мәдәни автономиясе 6 меңгә якын кешене берләштерә. Таҗиклар диаспорасы Татарстанның этномәдәни тормышына бик уңышлы үтеп керде. Күпмилләтле якшәмбе мәктәбендә таҗик телен өйрәтү өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган.

Таҗикстан Татарстан вузларында белем алучы чит илләр студентлары саны ягыннан беренче дистәгә керә (1 меңнән артыграк кеше белем ала – вузларда чит илләрдән килеп укучыларның гомуми саныннан 5 процент).

Парламент башлыгы ватандашлар белән берлектә эшләү мәсьәләләренә аерым тукталып үтте. Биредә сүз Таҗикстанда яшәүче татарлар, иҗтимагый оешмалар, республика хакимияте органнары белән хезмәттәшлек турында гына түгел, гомумән, Россиянең рус телле кешеләргә ярдәм итеп килүе турында бара. Хәзерге вакытта Таҗикстанда биш рус мәктәбен төзү төгәлләнеп килә. Парламентара форумда катнашучылар шуларның берсендә булды.

«Таҗикстан – Россия» парламентара форумының җиденче тапкыр үткәрелүе бу. Форум ике дәүләт төбәкләренең үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен карап тикшерү өчен абруйлы мәйданчыкка әйләнде.

БЕРӘҮ ДӘ ЧИТТӘ КАЛМАЯЧАК

«Яшь гвардия» штабының Татарстандагы вәкилләре «Бердәм Россия» партиясе белән берлектә Донецк һәм Луганск өлкәләреннән вакытлыча күчеп килүчеләр, эвакуацияләнергә мәҗбүр булганнар өчен гуманитар ярдәм җыя.

– Үз йортларын ташлап чыгып китәргә мәҗбүр булганнарның хәлен күз алдына китерәсездер. Күпләр иң кирәкле документларын да алырга өлгермәгән. Азык-төлек турында әйтмим дә инде. Без алар өчен кирәк-ярак, азык-төлек җыюны оештырдык. Бу турыда социаль челтәрләр аша гына хәбәр итсәк тә, инде ярдәм итәргә теләк белдерүчеләр шактый булды, – дип аңлатты «Яшь гвардия»нең төбәк оешмасы җитәкчесе Динар Бариев.

Берәү дә читтә калмаячак, ди алар. Чөнки ярдәм җыю пунктлары бөтен Россия буйлап эшләячәк. Ә ярдәмне исә кечегә яки зурга бүлеп карамаячаклар. «12 битле дәфтәр алып килсәләр дә, кабул итәчәкбез. Безнең өчен мөмкин кадәр күбрәк кешенең җәлеп ителүе мөһим», – диде Динар Бариев. Россиягә әти-әниләреннән башка килгән балалар да бар. Аларга ярдәм аеруча кирәк. Гомумән, «Яшь гвардия»челәр һәркемгә аерым игътибар бирелячәк дип вәгъдә итте.

Донецк һәм Луганск өлкәләреннән вакытлыча күчеп килүчеләргә ярдәм итәргә телисез икән, аны Казан шәһәре, Горький урамы, 12а адресы буенча кабул итәләр. Гуманитар штабның эш вакыты – иртәнге 8.00 сәгатьтән кичке 20.00гә кадәр.

Ничек ярдәм итә алабыз? Оештыручылар балалар өчен кирәк-яракның аеруча мөһим булуын искәртте. Моннан тыш, беренчел кирәк-ярак, саклану срогы зур булган азык-төлек, гигиена кирәк-ярагы (теш пастасы, теш щеткасы, сабын һ.б.), балалар өчен туклану продуктлары, 0–14 яшьлек балалар өчен китап һәм уенчыклар, канцелярия (каләм, дәфтәр, кайчы, балалар өчен буягычлар һ.б.), өй җиһазлары, көнкүреш техникасын да кабул итәләр. Мөмкинлектән чыгып, әйберләрнең яңа яисә яхшы сыйфатлы булуы зарур.

Элемтә өчен телефон:
+7 (910) 645-98-72 (Андрей).

МАЛЛАР НИК КИМИ?

Авыл хуҗалыгы

Татарстан ит һәм сөт белән үзен тулысынча тәэмин итә. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров еллык коллегия вакытында әнә шулай диде. Аның сүзләренә караганда, республикада бер кеше башына туры килә торган сөт һәм ит күләме нормадан артып китә. Шулай итеп, Татарстан сөтне – 37 процентка, итне 25 процентка күбрәк җитештерә.

Ләкин мондый яхшы күрсәткечләргә ирешсәк тә, узган ел хуҗалыкларда мөгезле эре терлек саны 31,7 мең башка кимегән. Шуларның 7,9 меңе – сыерлар. 24 районда маллар саны кимегән. Бары тик 19 район гына терлекләрне арттыруга ирешкән.

Министр сүзләренә караганда, хуҗалыкларда сыерлар сәламәтләндерү яки продуктивлылыгы тагын да югарырак булган малларга алыштыру максатыннан киметелгән. Димәк, кайбер хуҗалыкларда сыерлар кабат торгызылачак дигән сүз.

Мәсәлән, узган ел Кайбыч районындагы «Август Агро» оешмасында 12 мең мөгезле эре терлектән 7400е калган. Шуларның 1200е – савым сыеры. Ел башында фермаларда 3500 сөтлебикә булган. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Радик Камалетдинов әйтүенчә, ишле мал саны да районда нәкъ менә шушы оешмада булган. Җитәкче маллар торгызылачак, киметүнең сәбәбен сәламәт сыерларга алыштыру дип аңлаткан иде.

– Оешма 1200 сыерга исәпләнгән сөт комплексын төзи. Шунда бары тик сәламәт, продуктивлыгы яхшы булган малларны гына туплаячаклар. Терлек санын киметү сәбәбе әнә шул, – диде Радик Камалетдинов.

Шундый ук күңелсез хәл узган ел Арча районында да килеп чыккан иде. Район башлыгы Илшат Нуриев безнең белән сөйләшкән вакытта «Ак барс» хуҗалыгында 4 мең баш хайванны киметергә туры килгәнлеген әйткән иде.

Марат Җәббаров китергән мәгълүматлар буенча, терлек саннары кимегән хуҗалыкларның 30 проценты аларны кабат торгызырга җыенмый. Алар арасында терлекләрен 4600 башка киметкән «Кызыл Шәрык», 2000 башка киметкән «Чистай Агро», 1100әр баш малын югалткан Яшел Үзән һәм Спас районнарындагы «Авангард» җәмгыятьләре дә бар.

– «Кызыл Шәрык» агрофирмасы сөт күләмен 8 процентка киметте. Инвестор терлекчелек белән бөтенләй шөгыльләнми башлады. Алар 6,5 мең баш сыерын бетерде. Шулай ук «Ак Барс Холдинг»тагы терлекчелек белән бәйле вазгыять тә хафага сала. Алар елдан-ел сөт җитештерү күләмен киметә, – диде министр.

Мәсәлән, «Ак Барс Холдинг»ның Апас районындагы «Апас Мол» агрофирмасында терлекләр – 14 процентка, Әгерҗе районындагы «Нәүрүз» агрофирмасында 11 процентка кимегән. Шул ук вакытта шул ук холдингның уңышлы эшләп килүче агрофирмалары да бар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Инвестор – бер, әмма күрсәткечләр төрле. Уңышлы агрофирмаларның тәҗрибәләрен өйрәнергә һәм әлеге елны республикадагы уртача күрсәткечләрдән ким булмаган нәтиҗәләргә ирешергә кирәк, – диде Марат Җәббаров.

Терлек саны киму проблемасына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та тукталды.

– Авылларда терлекчелек өлкәсен үстерергә кирәк. Сөт җитештерүдән халыкка акча керә. Әгәр без сөтне эре хуҗалыкларда гына җитештерсәк, халык нәрсә белән шөгыльләнергә тиеш? Шуңа күрә әлеге мәсьәләнең социаль ягы да бар, – дип билгеләп узды Президент.

Зөһрә САДЫЙКОВА

УНСИГЕЗ ЯШЬЛЕК «БАБЫКАЙ»

Безнекеләр

Шушы көннәрдә хезмәттәшебез Камил абый Сәгъдәтшин 70 яшен тутырырга маташа әле. Болай дип әйтүем юкка түгел. 29 февральгә туры килгәнгә, быел календарьда юк аның туган көне. Моңа кадәр дә дүрт елга бер генә булган. Димәк, санап карасаң, аңа 18 яшь тә тулмаган булып чыга. Камил абыйның бу хәлләргә әллә ни исе китми. Нәрсә дисәң дә, 18 яшьлек егет булып йөрү начар эш түгел бит. Тик җиде дистә гомер барыбер үтеп киткән шул инде. Хезмәттәшем белән шул йомгакны сүтеп утырабыз.



Автор фотосы

Балачак

– Туган көнең юк дигәннән искә төште әле. Балачактан ук күңелемә кереп калган ул минем. Хәтерлисеңдер, ул вакытларда численник дип аталган календарьны стенага элеп куя торган гадәт бар иде. Әти кояш чыгышын, батышын, намаз вакытларын караштыргалап, көн саен бер битен ертып ала иде. Шуңа карап, абый-апалар туган көннәрен көтә. Мин дә көтәм. Берзаман килеп җитте дә кебек, ә бите юк. Югалып калмадым, кәгазь битенә 29 дип яздым да календарьга ябыштырып куйдым.

Газетага беренче язмамны да 3 нче сыйныфта укыганда ук язган идем. Язасы килгәннән дә түгел, сәбәбе башка иде аның. Без гаиләдә 11 бала үстек. Сирәк-мирәк барыбыз бергә тезелешеп утырган чаклар да була иде. Әни шундый вакытларда: «Столовой кадәр бит бу», – дип әйтә торган иде. Матди кыенлыклар булгандыр инде. Хезмәт хакы да бирелми иде бит. Бервакыт шулай газетага язган өчен акча, ягъни мәсәлән, гонорар бирәләр икән дип ишеттем. Укытучым белән киңәштем дә районга мәкалә язып җибәрдем. Бастырдылар. Инде көтә-көтә онытa да язган идем, хат ташучы китереп бирде. 78 тиен иде ул. Язу эшенә шушы әйбер тартып кертте бугай мине. Аннан: «Әнә кәрриспәндит килә», – дип, кызлар үрти башлады. Газетага язып җибәрмәсен тагын дип, шикләнәләр дә иде әле. Шулай итеп, абруем бермә-бер үсте.

Студент

– Мин Роберт Миңнуллин белән бер бүлмәдә яшәдем, Марсель Галиев, Ринат Мөхәммәдиев белән бер чорда укыдым. Яңа гына авылдан килгән малай өчен бу бик зур бәхет иде. Иҗат юлына кереп китүемә, мөгаен, моның тәэсире булмый калмагандыр. Робертның шигырь язмаган көне юк иде. Ринат кечкенә күләмле хикәяләр язу белән мавыкты. Бервакыт шулай, бер көн эчендә кем күпме яза дип, ярыша башладылар болар. Без Хәлим Айсин исемле егет белән жюри булдык. Мин дә язгаладым. Әмма шигырьләремне башкаларга сирәк күрсәттем. Робертның бер шөгылен үрнәк итеп алмаганыма гына үкенгән чакларым булды. Ул һәр мизгелне ничектер теркәп, тарихка кертеп калдырырга тырыша иде. Мин булдыра алмадым шул.

Журналист

– Татар матбугатында эшли башлавыма 40 елдан артып китте. Шуның 30 елы – «Ватаным Татарстан»да. Көн саен диярлек авыл хуҗалыгы проблемаларын күтәреп яздым да яздым. Авыл хуҗалыгы ул шундый тармак: белгән саен белмәгәнеңне күбрәк аңлыйсың. Соңгы еллар – колхозлар таркалу, инвесторлар килү, фермерларга эшләргә аяк чалу күренешләре бик күңелгә тиде. Авылда бөтен күңелен биреп эшли торган фермерларга ярдәм итәсе иде. Җирне яраткан кеше халкын да ярата. Акчасыз да калдырмый. Табыш алырга гына йөргән кайбер инвесторларны тизрәк куып җибәрәсе иде. Кимчелекләр гел күзгә чалынып торгач, тәнкыйтьләргә дә туры килде. Бервакыт үз районыбызның башлыгы, ичмасам, син генә булса да кыйнама инде, дигән иде миңа. Нишлисең, халык мәнфәгатен яклап йөргәч, анысы да булгалады. Кайбер районнарда эшләр судка кадәр барып җитте. Соңгы вакытта «Суд залыннан» рубрикасын алып барам. Андагы язмышлар тагын да аянычлырак.

Татар журналистикасының киләчәге өчен бик борчылам. Әзме-күпме файдасы тимәсме дип, кызыксындыру йөзеннән, 2017 елны махсус премиямне дә булдырган идем. Беренчесен гел егетләргә генә тәгаенләдем. Хәзер егетләр журналистикага килергә атлыгып тормыйлар бит. Аңлашыла инде, матди дөнья аларны күбрәк кызыксындыра. Стипендиянең күләме бик аз бит. Әмма ярап куя. Мин үзем 30 сум алып укыдым. Әлки районында апам яши иде. Ул, конвертка тыгып, 1 тәңкә акча җибәргәләде. Шуны ничек көтеп алганымны үзем генә беләм. Яшьләрне рухландырып җибәрү юлларын табасы иде. Якташлык җәмгыятен җитәкләгәч, инде ике срок район советы депутаты да булгач, туган ягым белән гел элемтәдә торам. Спас районыннан чыккан яшьләр белән дә очрашулар үткәрәбез. Туган авылым Иске Рәҗәптән ерак түгел Ирек дигән авыл бар иде. Шул авыл турында бергәләп китап язмакчы булабыз. Болгар якларының тарихын язып калдырасы килә. Бәлки, Ирекккә дә кемдер кайтып яши башлар.

Туган авыл

– Туган авылым Иске Рәҗәп тә – бай тарихлы авыл, тарихи чыганаклардан күренгәнчә, 1699 елны барлыкка килгән. Аңа кадәр дә ниндидер кабиләләр яшәгән дип сөйлиләр. Мин бәләкәй чакта Үзбәкстаннан кадәр кешеләр килеп, авылдан ерак түгел бер урында, изге җир дип, дога кылалар иде. Соңгы вакытта күренмиләр инде. Әмма борынгы ташлар сакланган. Аларны, Болгар өчен шәһит киткәннәргә куелган, диләр. Безнең авыл бәрәнҗәрләр кабиләсе белән дә бәйләнгән. Элеккеге исеме дә Иске Бәрән иде аның. Аны алыштыру вакыйгасы да бик кызыклы. Бервакыт шулай университетта укып йөргәндә бер авылдаш килеп чыкты. Авылга кайтып китә алмадым, сөйләшү пунктына барып, хатынга әйтеп килик әле, ди. Заказ бирдек тә утырабыз шулай көтеп. Бервакыт, Старый Баран, 7 нче кабина, дип кычкырмасыннармы?! Бөтен кеше гаҗәпләнеп безгә әйләнеп карады. Оялып, беркавым урыныбыздан кузгала алмый утырдык. Кеше аның «бәрәнҗәрләр» сүзеннән килеп чыкканын белми бит инде. Шуннан тарих укытучысы Зиннәтулла абый Гыйззәтуллин, хезмәттәшем Сәмигулла абый Хәйретдинов белән сөйләштек тә, озак кына йөри торгач, авыл исемен үзгәртә алдык. Көчле рухлы, белемле шәхесләр күп чыккан безнең авылдан. Бу җәһәттән бер генә әйберне искә алып китәм: мин укыган сыйныфта 33 баладан 27се югары уку йортын тәмамлады.

Иҗат

– Мин шигырьне төшемдә язам. Сикереп торып теркәп куймасам, шул килеш онытылып киткәннәре дә байтак. Әле юбилей уңаеннан бераз актарынып утырган булдым. Ун китабым дөнья күрде инде. Тагын байтак шигырь җыелган икән. 100гә якын җырым бар. Минем, көй язгыгыз әле дип, бер генә шигыремне дә композиторларга илтеп биргәнем юк. Әйтергә кирәк, бу – минем кимчелегем. Җыр сүзләре көй булып яңгырарга тиеш, югыйсә ул онытылырга мөмкин.

Гаилә

– Балаларым, оныкларым – минем өчен терәк тә, таяныч та. «Бабыкай» дип янымда бөтерелеп кенә йөриләр. Әбекәйләре Фәйрүзә дә алар өчен җанын бирергә әзер иде. Бергәләп сәяхәткә барып кайтырга да кыенсынмады. Шөкер, күңелем тыныч: Илдар да, Диләрә дә, эшебезне дәвам итеп, милләт өчен, халык өчен дип тырышалар. Улыбыз Татарстан китап нәшриятын җитәкли, Финанс министрлыгының матбугат үзәгендә эшләүче кызыбызны да каләме дә, күзе дә үткен дип мактыйлар. Оныгыбыз Азалиянең ике китабы дөнья күрде инде. Барысын да әбекәенең киңәшләренә таянып эшләде. Оныкларым татарча гына сөйләшәләр, кайчагында мине дә төзәткәләп җибәрәләр.

Бурыч

– Башлаган эшләрем бар әле минем. Ул тарих белән бәйле. Моннан күп еллар элек, көчләп чукындырудан качып, бабам авылдашлары белән Төркиягә юлга чыга. Әтием Шәмгун тиф белән авырып китә дә, аңа чикне чыгарга рөхсәт итмиләр. Хастаханәдә калдырганда, килеп алабыз, дип вәгъдә итәләр. Ул чакта аңа 11 яшь була. Терелгәч тә, бик озак көтә ул аларны. Ахыр чиктә Үзбәкстан аша җәяүләп кайтыр юлга чыга. Туган авылына 4 ел ярым кайта ул. Интегүләр моның белән генә бетми әле. Сугышта әсирлеккә төшеп, гаиләсенә кара кәгазь килә. Әйләнеп кайтканда хатыны Миңнегөл апа Миңнебай абый белән яши башлаган була. Яңа гаилә кора. И, ул чактагы колхоз тормышының авырлыклары! Терлек асрарга да ярамады. Тикшерергә килсәләр, күрмәсеннәр дип, бозауларны идән астына яшереп куя идек. Рәхәтләнеп йоклаганын да хәтерләмим мин әтинең. Әмма нинди генә авырлыкларга юлыкса да, безне укытты, кеше итте. Менә шушы вакыйгаларны авыл тарихы белән бәйләп, китап язасым килә. Әти алдындагы бурычым бу минем.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 10 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «в» пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), «бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан каралтылар,» сүзләреннән соң «мәйданы 15 квадрат метрдан артмаган, башка җир кишәрлекләрендә урнашкан каралтылар, мәйданы 15 квадрат метрдан артмаган, күпфатирлы йортларда, гараж комплексларында урнашкан торак урын булмаган биналар,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 21 февраль
№ 1-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 10 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6^3 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль район, шәһәр округы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны кимендә 500 берәмлек тәшкил итә;»;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»
Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен яңа мәҗбүри таләпләр билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган мәҗбүри таләпләрне үзгәртә торган, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеге

1) Әгерҗе муниципаль районы;
2) Азнакай муниципаль районы;
3) Актаныш муниципаль районы;
4) Алексеевск муниципаль районы;
5) Әлмәт муниципаль районы;
6) Арча муниципаль районы;
7) Баулы муниципаль районы;
8) Балтач муниципаль районы;
9) Бөгелмә муниципаль районы;
10) Буа муниципаль районы;
11) Югары Ослан муниципаль районы;
12) Биектау муниципаль районы;
13) Алабуга муниципаль районы;
14) Зәй муниципаль районы;
15) Зеленодольск муниципаль районы;
16) Кукмара муниципаль районы;
17) Лаеш муниципаль районы;
18) Лениногорск муниципаль районы;
19) Мамадыш муниципаль районы;
20) Менделеевск муниципаль районы;
21) Минзәлә муниципаль районы;
22) Түбән Кама муниципаль районы;
23) Нурлат муниципаль районы;
24) Питрәч муниципаль районы;
25) Балык Бистәсе муниципаль районы;
26) Саба муниципаль районы;
27) Сарман муниципаль районы;
28) Тукай муниципаль районы;
29) Чистай муниципаль районы;
30) Чаллы шәһәре.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 21 февраль
№ 2-ТРЗ

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 10 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2^1 статьяның 3 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 9^1 пункт өстәргә:

«9^1) тәмамланмаган капиталь төзелеш объектларының региональ реестрын булдыру һәм алып бару;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9^2 пункт өстәргә:

«9^2) капиталь төзелеш объекты Татарстан Республикасы милкендә булган очракта, капиталь төзелеш объекты авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану турында карар кабул итү;»;

2) түбәндәге эчтәлекле 19^7 статья өстәргә:

«19^7 статья. **Төзелүе, реконструкцияләнүе тулысынча яисә өлешчә Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган тәмамланмаган төзелеш объектлары**

1. Төзелүе, реконструкцияләнүе тулысынча яисә өлешчә Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган һәм төзелеп, реконструкцияләнеп бетмәгән тәмамланмаган төзелеш объекты, аның турындагы белешмәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55^{34} статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләр буенча тәмамланмаган капиталь төзелеш объектларының региональ реестрына кертелгән көннән алып, тәмамланмаган капиталь төзелеш объекты итеп таныла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55^{34} статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләр белән бергә, төзелеп, реконструкцияләнеп бетмәгән капиталь төзелеш объектларын төзелүе, реконструкцияләнүе тулысынча яисә өлешчә Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылган тәмамланмаган капиталь төзелеш объектларына кертүнең башка нигезләре каралырга мөмкин.

3. Төзелүе, реконструкцияләнүе тулысынча яисә өлешчә Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылган һәм төзелеп, реконструкцияләнеп бетмәгән капиталь төзелеш объектлары әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән тәмамланмаган капиталь төзелеш объектларының региональ реестрына кертелергә тиеш тәмамланмаган капиталь төзелеш объектларына карый.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында төзелүе, реконструкцияләнүе тулысынча яисә өлешчә Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылган тәмамланмаган капиталь төзелеш объектлары кертелә торган тәмамланмаган капиталь төзелеш объектларының региональ реестрын алып бару каралырга мөмкин.

5. Тәмамланмаган капиталь төзелеш объектларының региональ реестрын булдыру һәм алып бару тәртибе, аңа кертелә торган белешмәләр, мондый белешмәләрне бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 21 февраль
№ 3-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы баш агрономы **Занина** Любовь Николаевнага, «Семушкин Юрий Анатольевич» крестьян (фермер) хуҗалыгы агрономы (Татарстан Республикасының Спас районы) **Осипов** Владимир Николаевичка, «Актаныш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Сәләхов** Мирас Мәүләү улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Кама Беконы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 5300 комплексы 4 номерлы участогында терлекчелек комплекслары һәм механикалаштырылган фермалар операторы **Гыймалетдинов** Фәнис Әгъзам улына, «Наратлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча технологы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Исламова** Альбина Әхияр кызына, «Яңа Юраш» агрофирмасы» ябык акционерлык җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Алабуга районы) **Исхакова** Вәсилә Гыйльман кызына, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте филиалы «Ярател» кошчылык фабрикасы операторы-кош карачысы **Ирдинкина** Елена Петровнага, Никита Евдокимович Токарликов исемендәге акционерлык җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы **Сидорова** Татьяна Леонидовнага **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«П.В. Дементьев исемендәге агрофирма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Зур Аксу трактор паркы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Архипов** Николай Ивановичка, «БӨРЕЛЕ» ябык акционерлык җәмгыяте тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Машаев** Фәнис Шамил улына, «Апас-Мол» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Апас районы) **Миңнегалиев** Наил Талип улына. «Хезмәт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Ураков** Олег Дмитриевичка, «Бола» авыл хуҗалыгы предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте автомобиль йөртүчесе, комбайнчысы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Шиһапов** Фәрит Габделхак улына, «Яңа Юраш» агрофирмасы» ябык акционерлык җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Алабуга районы) **Галиев** Фәнис Әхкәметдин улына, «Бөрбаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Сабирҗанов** Нурислам Габдулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Алабуга Сөте» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Алексеева** Татьяна Михайловнага **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Хезмәт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Александрова** Валентина Петровнага, «Игенче» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы бригадиры (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Әхмәтгалиев** Нияз Мәгаз улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының хезмәтне саклау секторы әйдәүче белгече **Ефремова** Татьяна Гурьевнага, «АГРОКӨЧ» акционерлык җәмгыяте үсемлекчелек буенча башкарма дирекциясенең «Сәвәләй» җитештерү комплексы идарәчесе **Камалиев** Фоат Тәлвирт улына, «Сөләйманов Ильяс Галимҗан улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Сөләйманов** Ильяс Галимҗан улына, «ЭфЭмСи» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасындагы төбәк вәкиле (Мәскәү шәһәре) **Әхмәтов** Вагиз Газиз улына, «АгроЛак» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бригадиры (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Габдуллин** Илшат Нурмөхәммәт улына, «Марс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Зарипов** Рамил Шамил улына, «Таллы Бүләк» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Мотыйгуллина** Рәмзия Яшәр кызына, «П.В. Дементьев исемендәге агрофирма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Алешкино ремонтлау-механика хезмәтенең ремонтлау-механика остаханәсе мөдире (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Нурин** Василий Николаевичка, «Сөләйманов Әхтәм Исмәгыйль улы» крестьян (фермер) хуҗалыгының сөтчелек комплексы идарәчесе (Татарстан Республикасының Нурлат районы) **Нуретдинов** Рәмис Салих улына, «П.В. Дементьев исемендәге агрофирма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бүлекчәсе идарәчесе (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Сафин** Дамир Надир улына, «Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Фәткуллов** Илнур Заһит улына, «ӘНӘК» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бухгалтеры (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Хәмзина** Гөлсинә Гаян кызына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

Кадастровым инженером Мубаракшиным Рамилем Наиловичем (адрес: 422060, РТ, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Строителей, д. 4, помещение 1, тел.: (927) 442-67-78, e-mail: ramil40@yandex.ru, квалификационный аттестат 16-11-289) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:33:000000:209, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Шалинское сельское поселение, подготовлен проект межевания земельного участка.

Заказчиком проекта межевания земельного участка является Сафина Альбина Ахатовна (РТ, Пестречинский район, с. Шали, ул. Советская, д. 21; тел.: +7(917)2668988).

С проектом межевания земельного участка можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч. по адресу: РТ, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Строителей, д. 4, помещение 1 в течение 30 календарных дней со дня опубликования данного извещения.

В соответствии с Федеральным Законом от 29.12.2010 г. №435-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения» возражения относительно размера и местоположения границ, выделяемых в счёт земельных долей земельных участков должны содержать фамилию, имя и отчество лица выдвинувшего эти возражения, реквизиты документа, удостоверяющего личность, обоснование причин его несогласия с предложенным размером и местоположением границ выделяемых в счёт земельных долей, кадастровый номер исходного земельного участка. К этим возражениям должны быть приложены копии документов, подтверждающих права лица, выдвинувшего эти возражения, на земельную долю в исходном земельном участке.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счёт земельных долей земельного участка принимаются в письменном виде либо почтовым отправлением в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 422060, РТ, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Строителей, д. 4, помещение 1.



Бергә җыелганда



Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Хикәя

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

Мәүли йокысы

pixabay.com

Мәүли бүген дә йоклап, дәрескә соңга калды. Ишегалдында йөргән кикриксез әтәч тагын кычкырмаган, мөртәт! Мәүли тузына-тузына, портфелен асып, мәктәпкә йөгерде...

Көн саен шул хәл, көн саен! Класс житәкчесе Бибигайшә апасы тиргәп тә карады инде аны, бөтен класс алдында оялтып та карады, юк – Мәүли уянып сикереп торганда сәгать унберенче киткән була. Бүген Мәүли дәрестән соң авылның аргы очында яшәүче им-томчы Гөлҗиһан карчык янына барып кайтырга булды.

– И-и, балакаем, бер дә борчылма, – диде Гөлҗиһан әби сандыгында актарына-актарына, – менә шушы үлән тамырын кайнатып эчсәң, әтәч белән уянырсың, Аллаһы боерса, бер дә борчылма...

Кадерле үлән тамырын Мәүли түш кесәсенә тыгып, бер кулы белән тотып кайтты. Бер тыкрыкны узгач, малайга зур гына овчарка иярде, һич калышмый бара, дуңгыз!

– Рекс, – диде Мәүли ялварулы тавыш белән, – син үлән ашамыйсың бит, нәрсәгә инде ул сиңа? Аннары, синең иртүк торасың да юк, йокла шунда кояш баеганчы...

Исеме Рекс булмаса да, маэмай аңлады тагын – калды.

...Мәүли уянып киткәндә сәгать теле алтыны күрсәтә иде. Иртәнге кояш нурлары өй эченә саргылт төс индергән. Малай җырлый-җырлый юынды, куначада йоклап утырган кикриксез әтәчне уятып керде.

«Вәт бит, үләннең файдасы, вәт бит Гөлҗиһан әбинең файдасы, менә бит...» – дип сөенеп мыгырданды ул.

Мәктәпкә дә иң беренче булып килеп керде малай, хәтта Бибигайшә апасы да аңардан соңарып килде.

– Апа! – Мәүли, авызын ерып, укытучысы каршысына ашыкты. – Апа! Сенсация! Гөлҗиһан әби миңа үлән тамыры бирде, менә, шуны эчкәч, иртә уяндым...

Мәүли ялкынланып сөйләгән арада классташлары да җыела башлады:

– Йокы да туйган, баш та яхшы эшли, – дип дәвам итте Мәүли, үзе сөенеп, классташларына карады.

– Ярый, әйбәт булган, – диде Бибигайшә апасы, көлемсерәп, – тик кичә көне буе кайда булдың син, Мәүли? Дәрескә дә килмәдең, урамда да күрмәгәннәр сине... Кичә кайда булдың дим, Мәүли?!

Тизәйткечләр

Жылы җәйнең көннәрендә
җәймә тау итәгендә
җизни кызы Җәүһәрия
җиләк җыя чиләгенә.



Җиләк, җиләк, җиләкләр,
бик тиз тулмый чиләкләр.
Тулыр иде чиләге,
юк бит аның җиләге.

***

Җидегәндә – җиде кыз,
Җиргә якын ул йолдыз.
Җиргә якын Җидегәндә –
җиде йолдыз, җиде кыз.

АЛИЯР ЗӘЙДУЛИН:
«Хип-хоп матурлыгы белән җәлеп итте»

«Бергә җыелганда» сәхифәсенең бүгенге кунагы – хип-хопка гашыйк 9 яшьлек Алияр. Биергә кемнән күреп өйрәнгән ул? Хип-хоп нәрсәсе белән җәлеп иткән? Без әнә шулар турында сөйләштек.

:: Алияр, сине биергә ярата, дип ишеттем.
– Әйе, дөрес. 8 яшемдә хип-хоп белән шөгыльләнә башладым. Ул урам акробатикасының бер юнәлеше булып тора. Без биеп кенә калмыйбыз, төрле акробатик күнегүләр дә башкарабыз – миңа бу ягы аеруча ошый.

:: Син бу юнәлеш турында кайдан ишеттең?
– Башка балалар кебек, мин дә интернетта утырырга яратам. Вакытымны бушка уздырмыйм – үземнең яшьтәшләремнең кызыксынуларын барлыйм. Хип-хоп турында да 9–10 яшьлек малайлардан күреп белдем. Алар башкарган күнегүләр җиңел дә, шул ук вакытта бик стильле һәм матур кебек тоелды. Шул малайлардан кызыгып, мин дә хип-хоп белән шөгыльләнә башладым.

:: Синең хип-хоп белән шөгыльләнергә теләвең турында ишеткәч, әти-әниең нәрсә диде?
– Минем биергә яратуым турында апам бик яхшы белә иде. Мамадышта хип-хоп түгәрәге ачыла дигән белдерүне күргәч, ул шундук минем әниемә әйткән. Әти дә, әни дә каршы килмәде, үзебезнең шәһәрдә шөгыльләнер өчен мөмкинлек булгач, файдаланып карарга кирәк, диделәр. Беренче дәрестә үземне сынап кына карадым. Шундук ошаттым һәм мине яздыртуларын сорадым. Алар сөенде генә!

:: Остазың кем? Аның белән шөгыльләнү ошыймы сиңа?
– Без атнага ике мәртәбә «Квантум» балалар иҗаты үзәгендә җыелышабыз. Тренерыбыз – Илшат Марсович Шәймәрданов – бик ачык күңелле кеше. Күнегүләрне җайлап кына өйрәтә, гел ярдәм итәргә тора. Аның белән инде икенче елымны шөгыльләнәм. Быел менә дәрестән соң да 10–20 минутка калып, катлаулырак күнегүләр өйрәнергә гадәтләнеп киттек.

:: Дәресләрнең кайсы өлеше аеруча ошый?
– Акробатиканы яратам. Авыр булса да, акробатик күнегүләрне өйрәнү үзенчә кызык.

:: Авыр күнегүне башкарып чыкканнан соң, ниләр кичерәсең?
– Бик сөенәм! Акробатика зур тырышлык таләп итә. Нинди дә булса авыр элементны башкара алсам, аны камилләштерергә керешәм. Матуррак һәм төгәлрәк булсын өчен.

:: Нинди музыка тыңларга яратасың?
– Миңа R&B, поп кебек юнәлешләр ошый. Күбрәк инглиз телендәге җырларны тыңларга тырышам, чөнки бу телне начаррак беләм. Ә сүзләрен аңламагач, музыканы яхшырак тоясың.

:: Киләчәктә кем булырга телисең?
– Инженер-төзүче булырга хыялланам. Ә хип-хоп минем хобби булыр, дип уйлыйм.

:: Иң зур хыялың нинди?
– Япониягә барасым килә. Миңа аларның мәдәнияте ошый.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Кунагыбыз турында белешмә

- Алияр – Мамадыш егете.
- Шәһәрнең 1 нче санлы мәктәбендә 3 нче сыйныфта белем ала.
- Иң яраткан фәннәре – физкультура, математика һәм әдәбият.
- Буш вакытта рәсем ясарга ярата.

Безгә язалар

КЕШЕ УРЫНЫНА – РОБОТ

Бүген кешеләр эшләрен роботлар эшли. Машиналар да кешесез йөри ала. Иннополиста шундый такси йөри. Әлегә ике генә пилотсыз машина. Чакырткач, ул килеп җитә. Аннары, утыргач, бара башлый. Ләкин алдагы пассажир урынында тикшерүче утыра. Ул машинаның маршрут буенча баруын тикшерә. Таксины чакырганда пассажир кушымтадан маршрутны билгели. Тагын Иннополиста «робот-курьер» бар. Аның эше кафедан кешегә ризыкны алып килү. Ул робот алты тәгәрмәчтә йөри. Кемнеңдер соравы туар: ә ул робот ничек күрә һәм кая барасын кайдан белә? Роботта камералар, радар һәм «лидар» дигән әйберләр бар. Шулай ук ул да маршрут буенча бара. Аның капкачы кушымтадан гына ачыла. Буш булганда аның массасы – 70 кг, максималь тизлеге – 8 км/сәг.

Сабир СӘФӘРОВ,
Казан шәһәренең 2 нче татар гимназиясе укучысы

МИНЕМ ПЕСНӘКЛӘРЕМ

Мәктәптә алган яхшы билгеләрем белән әниемне сөендерим дип, ашыга-ашыга өйгә кайтып киләм. Аяк астында кар шыгырдый. Кышкы кояш нурларында кар бөртекләре җем-җем итә. Подъезд ишегенә якынлашканда икенче каттагы балконнан тавыш ишетелде:

– Камил, кара әле, песнәкләр килгән!

Күрше Сания апа икән.

– Сания апа, ялгышасыңдыр, песнәкләр җылы якка китми бит, – дидем мин.

Сания апа минем сүзләргә колак та салмады, гөр-гөр килеп кошлар белән сөйләшүен дәвам итте. Миңа бу кызык тоелды, туктап, Сания апаны күзәтә башладым.

Миләш агачында дүрт-биш песнәк утыра. Алар алмаш-тилмәш Сания апаның балконы янына очып баралар да кире миләш агачына әйләнеп кайталар. Кара син аларны! Сания апаның кулыннан ипи валчыклары чүпли икән бит алар.

– Минем узган елгы песнәкләрем болар! – диде Сания апа.

Чыннан да, узган ел Сания апа кыш буе унлап песнәкне кулыннан ашатырга өйрәтте. Песнәкләр башка кеше кулыннан җим алмыйлар, бары тик Сания апа янына гына киләләр. Күрше апаның балконга чыгып басуы була, песнәкләр шундук сырып та алалар иде. Тик көннәр җылыткач, песнәкләр юкка чыкты. Сания апа аларны бик юксынды. Ә песнәкләр Сания апаны онытмаганнар икән бит!

Шундый киң күңелле күрше апам булу белән горурланып өйгә кереп киттем. Кичен әтием белән песнәкләргә җимлек ясадык. Икенче көнне җимлеккә ипи валчыклары, ярма салып элеп тә куйдык. Мәктәптән кайтканда җимлектә утыручы песнәкләрне күреп сөендем. Алар миңа рәхмәт әйткән шикелле тоелды.

«Рәхмәт сиңа, Сания апа! Минем дә үз песнәкләрем бар хәзер», – дип уйладым мин.

Ә күңелемдә шигырь юллары барлыкка килде:

И песнәкләр, килегез сез,
Туңып йөрмәгез кышта!
Ашап, җылынып алыгыз,
Салкын булса да тышта!

Камил ГАЙНУЛЛИН, 12 яшь.
Минзәлә районы

Башыңны эшләт

Тәмле дә, төрле дә!

Шоколад яратмаган кеше бармы икән ул? Балалар аеруча ярата бит, шулаймы? Ә сез әлеге тәм-том турында нәрсә беләсез? Белемегезне тикшереп карарга тәкъдим итәбез.

1. Шоколадның ватаны.
А) Россия;
Б) Үзәк һәм Көньяк Америка;
В) Чехия.

2. Шоколадлы сөт эчемлеген кем уйлап тапкан?
А) Ганс Слоан;
Б) Антон Чехов;
В) Мел Гибсон.

3. Санап үтелгән шәһәрләрнең кайсында шоколад музее бар?
А) Кёльн;
Б) Әлмәт;
В) Казан.

4. Бер көнгә күпме күләмдә шоколад ашарга рөхсәт ителә?
А) Күпме телисең, шулкадәр ашарга рөхсәт;
Б) 1 кг;
В) 40 г.

5. Гиннесс китабына кергән шоколадның авырлыгы күпме?
А) 10 тонна;
Б) 100 кг;
В) 6 тонна.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) А; 4) Б; 5) В.

КОЯШ – ТӨП ЙОЛДЫЗЫБЫЗ



Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 228

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+